Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район

Күки авыл җирлеге Советы

КАРАР №3

Күки авылы 2026 елның 6 феврале гыйнвары

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2025 елның 24 декабрендәге “2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге бюджеты турында”гы 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив актны законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Күки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советының 2025 елның 24 декабрендәге “2026 елга һәм 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге бюджеты турында”гы 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Карар преамбуласында «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсендәге 10 өлешнең 2 пункты» дигән сүзләрне «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе” дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы,Күки авылы, Яңа урамы, 5 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов